ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«26» август 2021 ел **№ 608**

**Каты көнкүреш калдыклары полигонына карата концессион килешү төзү һәм әлеге объектны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районына концессиягә тапшыру буенча чаралар планын ("юл картасы") раслау турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты карар бирде:

1. Каты көнкүреш калдыклары полигонына карата концессион килешү төзү һәм әлеге объектны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районына концессиягә тапшыру буенча чаралар планын ("юл картасы") расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Р.Р. Фазыловка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Мөхәрәмов

Расланды

Арча муниципаль районы

башкарма комитеты җитәкчесе

_______________________ Р.Р. Мөхәрәмов

«___»________________ 20 _ ел

Каты көнкүреш калдыклары полигонына карата концессион килешү төзү һәм әлеге объектны ТР Арча муниципаль районына концессиягә тапшыру буенча чаралар планы («юл картасы»)

| № | Чаралар исеме | Вакыты | | Документлар | | Норматив хокукый акт |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Концессион килешү (алга таба – КК) объектлары исемлеген формалаштыру: | Ызанлау эшен әзерләү датасы | Техник планны әзерләү датасы | Квартал | Җир кишәрлеге (кадастр номеры) | «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясы |
| | Каты көнкүреш калдыклары (алга таба -ККК) полигоны | үтәлде | үтәлде | | 16:16-17/009/2008-301 | Дәүләт теркәве турында таныклык |
| | Гаражы булган административ көнкүреш корпусы | үтәлде | үтәлде | | 16:16-17/009/2008-303 | Дәүләт теркәве турында таныклык |
| | ККК полигонын урнаштыру өчен җир кишәрлеге | үтәлде | үтәлде | | 16-16-10/004/2012-014 | Дәүләт теркәве турында таныклык |
| 2 | 10 елга кадәр каты көнкүреш калдыклары полигоны объектына карата 2012 елның 26 декабрендәге 3 номерлы концессион килешү (2021 елның 26 декабренә кадәр) | үтәлде | үтәлде | | | Килешү дәүләт теркәвенә алынды 15.03.2012 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3 | КК объектына техник тикшерү үткәрү.<br>Техник тикшерү махсуслаштырылган оешманы җәлеп итеп үткәрелде | 24.05.2018 | Арча шәһәре каты көнкүреш калдыклары полигонына экологик аудит үткәрү турында хисап | |
| 4 | Гамәлдәге килешү срогы тәмамлануга бәйле рәвештә, Арча шәһәре каты көнкүреш калдыклары полигоны объектына карата ККне яңадан төзү турында карар кабул итү. (ККнең гамәлдә булу вакыты 2021 елның 26 декабренә кадәр.)<br><br>КК төзү турында карар кабул итү (муниципаль район администрациясе).<br>Карарның эчтәлегенә карата таләпләр 2 п., 2.1.,2.3., 22-ФЗ-115 ст.<br>Карар кабул итү өчен концессион килешү шартлары формалаша:<br>1) КК объектын төзү һәм (яисә) реконструкцияләү буенча концессионер йөкләмәләре, аны төзү һәм (яисә) реконструкцияләү срокларын үтәү;<br>2) КК тарафыннан каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру буенча концессионер йөкләмәләре;<br>3) КК гамәлдә булу срогы;<br>4) КК объектының тасвирламасы;<br>5) җир кишәрлекләрен концессионерга бирү тәртибе, аренда шартнамәләре (субаренда) төзү срогы;<br>6) КК объектыннан файдалану (куллану) максатлары һәм вакыты;<br>7) башка әһәмиятле шартлар. | 17.12.2021 | Муниципаль районның җирле үзидарә органы карары | РФ Хөкүмәтенең 22.08.2011 № 1493-р күрсәтмәсе «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы |
| 5 | Концессион килешү төзү өчен конкурс документларын әзерләүдә үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү максатында Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына мәгълүмат җибәрү: | Объектны концессиягә тапшыру турында карар кабул ителгәннән соң 15 эш көне | Концессион килешү төзү өчен документлар | РФ Хөкүмәтенең 22.08.2011 № 1493-р күрсәтмәсе «Концессион килешүләр турында» |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы |
| 6 | Конкурс документларын эшләү һәм раслау<br>Концессион килешү төзү хокукына конкурс документларына таләпләр ФЗ - 115 статьясында билгеләнгән | 01.03.2022 | Конкурс документлары | «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы |
| 7 | Арча муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы тарифлар буенча дәүләт комитетына (алга таба - Комитет) концессион килешү төзү өчен конкурс документациясен әзерләүдә үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү максатында түбәндәге мәгълүматны җибәрү: | 30.03.2022 | Татарстан Республикасы тарифлар буенча дәүләт комитетына КК төзү хокукына конкурс документларын килештерү турында рәсми хат | «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 8 | Алган мәгълүматны һәм хәбәрнамәне бастырып чыгаруны исәпкә алып, конкурс документларын эшләү һәм раслау.<br>Концессион килешү төзү хокукына конкурс документларына таләпләр ФЗ - 115 статьясында билгеләнгән.<br>*Россия Төзелеш министрлыгы, концессион килешүләр турында Россия Федерациясе законнарын исәпкә алып, коммуналь инфраструктура объектларына карата концессион килешү төзү хокукына ачык конкурс документларын әзерләде.*<br>*Әлеге Документлар Министрлыкның рәсми сайтында "Документлар" - "Коммуналь инфраструктура системасына карата концессион килешү төзү хокукына ачык конкурс үткәрү буенча Конкурс документлары" бүлегендә урнаштырылган http://minstroyrf.ru/docs/3603/*<br>Конкурс уздыру турындагы хәбәр конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнгән рәсми басмада | конкурс документларында билгеләнгән срокта, әмма конкурста катнашуга заявкалар бирү срогы тәмамланганчы кимендә 30 эш көне кала | Йомгаклау<br>Татарстан Республикасы тарифлар буенча дәүләт комитеты | «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | бастырып чыгарыла һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырыла. | | | |
| 9. | Конкурс тәкъдимнәре кертү һәм конкурс тәкъдимнәре язылган конвертларны ачу, конкурс тәкъдимнәре язылган конвертларны ачу беркетмәсен төзү һәм имзалау. | хәбәрнамәләр җибәрелгән вакыттан алып кимендә алтмыш эш көне эчендә | Конкурс үткәрү Арча муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләреи палатасы | «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 10 | Нәтиҗәләр ясау, җиңүчене билгеләү һәм конкурс уздыру нәтиҗәләре турындагы беркетмәне имзалау | 15.07.2022 | Концессион килешу төзү | «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон |